СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**«_31_ »_гыйнвар_ 2024 ел** **№ _262_**

**«Арча муниципаль районы бүләкләрен гамәлгә кую турында» 2006 елның 10 февралендәге 44 номерлы Арча район Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (23.01.2018 № 158, 14.03.2019 №231, 11.12.2020 № 31 үзгәрешләр белән)**

Гражданнарны һәм коллективларны Арча муниципаль районының социаль-икътисади һәм мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен бүләкләү тәртибен камилләштерү, аларның Арча муниципаль районы алдындагы казанышларын тану, районның иҗтимагый тормышындагы хезмәтне һәм активлыкны стимуллаштыру максатыннан, Арча район Советы карар бирде:

1. «Арча муниципаль районы бүләкләрен гамәлгә кую турында» 2006 елның 10 февралендәге 44 номерлы Арча район Советы карарына (23.01.2018 №158, 14.03.2019 №231, 11.12.2020 №31 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертергә һәм яңа редакциядә расларга:

1.1. Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә;

1.2. Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә;

1.3. Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты бланкын 3 нче кушымта нигезендәге редакциядә;

1.4. Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы бланкын 4 нче кушымта нигезендәге редакциядә;

1.5. Арча муниципаль районы бүләкләре белән бүләкләү өчен тапшырыла торган материалларны карау комиссиясе составын 5 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары А.Ф. Мөхәмәтовага йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г.Нуриев

Арча район Советының
31 гыйнвар 2024 ел, № 262 карары белән
расланды

## Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы турында нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) документлар тапшыру һәм гражданнарны, оешмаларны Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләү тәртибен билгели.

2. Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы (алга таба - Мактау грамотасы) Арча муниципаль районы территориясендә эшләүче яисә яшәүче гражданнарны, шулай ук Арча муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып бара торган предприятие, учреждение һәм оешмаларны бүләкләү рәвеше булып тора.

3. Мактау грамотасы белән бүләкләү өчен түбәндәгеләр нигез була:

- күпьеллык намуслы хезмәт;
- икътисад үсеше өлкәсендәге казанышлар һәм уңышлар;
- социаль өлкәдәге казанышлар һәм уңышлар;
- мәдәният, сәнгать һәм спорт өлкәсендәге казанышлар һәм уңышлар;
- мәгариф һәм тәрбия өлкәсендәге казанышлар һәм уңышлар;
- сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлар һәм уңышлар;
- әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсендәге казанышлар һәм уңышлар;
- законлылык, хокук тәртибе һәм җәмәгать куркынычсызлыгы өлкәсендәге казанышлар һәм уңышлар;
- эшкуарлык эшчәнлеген оештыруда мөһим уңышлар;
- хәйрия һәм җәмәгать эшчәнлегендә актив катнашу;
- хезмәт һәм җитештерү уңышлары;
- массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүдәге уңышлар;
- һөнәри бәйрәмнәр;
- хезмәт коллективлары һәм оешмалары өчен юбилей даталары (оешкан көннән соң 10 ел һәм аннан соң 5 ел саен);
- гражданнар өчен юбилей даталары (50 яшькә җиткәч һәм аннан соң 5 ел саен).

4. Тиешле структур бүлекчә яисә, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, оешмалар, предприятиеләр җитәкчеләре хезмәт коллективын яисә билгеле бер затны бүләкләү турындагы үтенечнамәне (Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы турындагы нигезләмәгә 1 нче, 2 нче кушымталар), бүләкләүне нигезләп, Арча муниципаль районы башлыгы исеменә кертәләр.

5. Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы мәсьәлә буенча Арча муниципаль районы башлыгы, үтенечнамә бирмичә генә, шәхсән үзе инициатива күрсәтергә хокуклы.

6. Мактау грамотасы белән бүләкләүгә Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты булган затлар тәкъдим ителә, моңа аерым казанышларда чагыла торган очраклар керми.

Гражданны Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләгәндә тармакта кимендә 5 ел нәтиҗәле хезмәт булуы мәҗбүри шарт булып тора.

7. Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы үтенечнамәгә кушымта итеп түбәндәгеләр бирелә:

- гражданнар өчен - бүләкләүгә тәкъдим ителүче гражданның район үсешенә керткән өлешен чагылдыра торган тәгаен казанышларын һәм хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр күрсәтелгән җентекле характеристика;

-милек рәвешенә бәйсез рәвештә, предприятиеләрнең, учреждение һәм оешмаларның җитәкче составы затлары өчен район үсешенә керткән тәгаен казанышлары һәм хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр күрсәтелгән җентекле характеристика, предприятиенең социаль-икътисади хәле, салымнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмау, предприятиенең соңгы өч елдагы төп финанс-икътисади күрсәткечләре динамикасы турында белешмәләр (белешмәләрнең гамәлдә булу срогы - 3 ай);

- хезмәт коллективлары һәм оешмалары өчен - социаль-икътисади, фәнни һәм башка казанышлар турында белешмәләр, юбилей датасына бәйле рәвештә бүләкләгәндә - учреждение оешу датасы турында белешмә, устав яисә башка гамәлгә кую документының күчермәсе.

8. Үтенечнамәдә бүләкләүгә тәкъдим ителә торган граждан турында белешмәләр (фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы) шәхесне таныклый торган документ нигезендә, коллективлары Мактау грамотасы белән бүләкләүгә тәкъдим ителә торган орган яисә оешманың исеме гамәлгә кую документлары нигезендә язылa.

Үтенечнамәне тутырганда нинди дә булса кыскартулар, аббревиатуралар, төгәлсезлекләр һәм төзәтүләр рөхсәт ителми.

Үтенечнамәгә имза салучы затлар анда күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеген тәэмин итәләр.

9. Бары тик юбилей датасына бәйле рәвештә генә Мактау грамотасы белән бүләкләүгә тәкъдим итү рөхсәт ителми.

10. Үтенечнамә, аңа беркетелгән документлар белән бергә, бүләкләү турында планлаштырылган тапшыру датасына кадәр 2 атнадан да соңга калмыйча Арча муниципаль районы башлыгына тапшырыла.

11. Бүләкләү турындагы карар Арча муниципаль районы башлыгы карары белән рәсмиләштерелә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла. Бер оешманың берничә хезмәткәренә үтенечнамә кергән очракта, Арча муниципаль районы башлыгының бер карарын рәсмиләштерү рөхсәт ителә.

12. Мактау грамотасы ике дәүләт теленең берсендә: рус һәм татар телендә языла. Үтенечнамә Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасын рәсмиләштерү күздә тотылган телдә рәсмиләштерелергә тиеш.

13. Мактау грамотасы Арча муниципаль районы башлыгы тарафыннан имзалана.

14. Бүләкләнүчегә Мактау грамотасы тапшыруны Арча муниципаль районы башлыгы яисә ул вәкаләт биргән вазыйфаи зат тантаналы шартларда башкара.

Мактау грамотасын район башлыгы күрсәтмәсе буенча һәм аның исеменнән аның урынбасары, район башлыгы аппараты җитәкчесе, Башкарма комитет җитәкчесе, аның урынбасарлары, Башкарма комитетның структур бүлекчәләре җитәкчеләре тапшыра ала.

15. Үтенечнамә түбәндәге очракларда кире кагыла:

а) Мактау грамотасы белән бүләкләү өчен нигезләр булмау;

б) үтенечнамәдә булган белешмәләрнең дөрес булмавы ачыклану;

в) бүләкләүгә тәкъдим ителгән оешманың вазыйфаи заты вафат булу яисә коллектив бетерелү;

г) җинаять кылган өчен бүләкләүгә тәкъдим ителгән затның закон көченә кергән суд карары нигезендә гаепләнүе.

16. Бүләкләүдән баш тарту турында карар кабул ителгән затлар, күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән бер елдан да иртәрәк булмаган вакытта, яңа казанышлары булганда һәм бүләкләүдән баш тарту сәбәпләре юкка чыгарылган очракта, кабат тәкъдим ителү хокукына ия.

17. Арча муниципаль районы алдындагы яңа казанышлары өчен Мактау грамотасы белән кабат бүләкләү, кагыйдә буларак, алдагы бүләкләүдән соң кимендә 5 ел узгач мөмкин, район, республика, халыкара масштабтагы массакүләм чараларны һәм акцияләрне уңышлы әзерләгән һәм уздырган өчен, район файдасына күрсәтелгән каһарманлык, кыюлык һәм батырлык өчен бүләкләүдән тыш.

18. Арча район Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнүчеләрне исәпкә алуны Арча муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру-гомуми бүлеге башкара.

19. Мактау грамотасын югалткан очракта, дубликат бирелми.

20. Мактау грамоталарын әзерләүгә һәм аларга рамкалар сатып алуга бәйле чыгымнарны Арча муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслarга.

## II. Мактау грамотасының тасвирламасы

Мактау грамотасы бланкы китап ориентирлашуының А4 форматындагы тыгыз кәгазь битеннән гыйбарәт. Мактау грамотасы бланкы периметры буенча рамка белән уратып алынган. Бланк уртасында өстә Арча муниципаль районы гербы сурәтләнгән. Астарак «Мактау грамотасы» исеме, аннары бүләкләнүче затның казанышларын кыскача тасвирлау, «бүләкләнүче» сүзе, бүләкләнүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, бүләкләнүче затның вазыйфасы күрсәтелә.

Бүләкләнүче турындагы белешмәләр текстыннан астарак Арча шәһәрендәге истәлекле урыннарның алтынсу төстәге контурлы сурәте урнаштырылган.

Бланк уртасында аста имза, «Арча муниципаль районы башлыгы» сүзләре һәм имзаның Арча муниципаль районы башлыгының исеме һәм фамилиясе, атасының исеменнән торган аңлатмасы язылган.

Астарак «Арча» сүзе урнашкан һәм бүләкләү елы өтер аша күрсәтелгән.

Мактау грамотасы язулары Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә - рус һәм татар телләрендә башкарыла.

Мактау грамотасы бланкы өчен алтынсу һәм кара төсләрдәге Times New Roman хәрефләре кулланыла.

Мактау грамотасы бланкы өчен өстәмә атрибут - пыялалы рамка каралган.

*Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы турындагы нигезләмәгә*
*1 нче кушымта*

Арча муниципаль районы башлыгы
___________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

ҮТЕНЕЧНАМӘ

Сездән Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләү өчен

_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
(бүләкләүгә тәкъдим итү нигезе)

_______________________________________________________________________________
бүләкләү өчен кандидатның эшләү урыны, [1]вазыйфасы)

______________________ кандидатурасын каравыгызны сорыйм.

(ФИАи, туу датасы)

Кушымта: тәгаен казанышларын һәм белешмәләрне күрсәтеп, хезмәт эшчәнлеге турында характеристика.

Оешма,
предприятие, учреждение һ.б. җитәкчесе

(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

---

[1] *Әгәр орган яисә оешманың исеме органның гамәлгә кую документларында татар телендә күрсәтелгән булса, оешманың исеме рус һәм татар телләрендә күрсәтелә.*

*Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы турындагы нигезләмәгә*
*2 нче кушымта*

Арча муниципаль районы башлыгы

________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

ҮТЕНЕЧНАМӘ

Сездән Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләү өчен

________________________________________________________________________________
(бүләкләүгә тәкъдим итү нигезе)

________________________________________________________________________________
(оешманың тулы исеме)[2]

үтенечнамәне каравыгызны сорыйм.

Кушымта: казанышлары турында белешмәләр, бүләкләү датасына бәйле рәвештә - оешмага нигез салыну датасы турында белешмә.

Оешма,
предприятие, учреждение һ.б. җитәкчесе

(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_________________________

[2] *Әгәр орган яисә оешманың исеме органның гамәлгә кую документларында татар телендә күрсәтелгән булса, оешманың исеме рус һәм татар телләрендә күрсәтелә.*

*Арча район Советының*
*31 гыйнвар 2024 ел,*
*№ 262 карары белән расланды*

**Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты турында нигезләмә**

1. Әлеге нигезләмә (алга таба-Нигезләмә) документлар тапшыру һәм гражданнарны, оешмаларны Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты белән бүләкләү тәртибен билгели.

2. Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты (алга таба - Рәхмәт хаты) икътисад, сәнәгать, фән, мәдәният, сәнгать, мәгариф, сәламәтлек саклау, спорт, җирле үзидарә үсешенә керткән аерым шәхси өлеше, законлылыкны, хокук тәртибен, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен яклау эшендәге казанышлар, район һәм аның халкы алдындагы башка казанышлар (уңышлар) өчен бүләкләү рәвеше булып тора.

3. Рәхмәт хаты белән бүләкләнәләр:

- гражданнар -күпьеллык намуслы хезмәте һәм районның социаль-икътисади, мәдәни үсешенә керткән шәхси өлеше, район алдындагы башка казанышлары өчен;

- предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның хезмәт коллективлары - хуҗалык, фәнни, социаль-мәдәни, иҗтимагый, хәйрия эшчәнлегендә район тормышын яхшыртуга керткән югары казанышлары өчен.

Бүләкләү өчен нигез булып һөнәри бәйрәм, юбилей датасы (хезмәт коллективлары һәм оешмалары өчен - оешкан көннән 10 ел һәм аннан соң 5 ел саен; гражданнар өчен юбилей даталары - 50 яшь тулгач һәм аннан соң 5 ел саен) торырга мөмкин.

4. Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында карар Арча муниципаль районы башлыгы тарафыннан үз инициативасы белән дә, Башкарма комитетның структур бүлекчәләре җитәкчеләре тәкъдиме буенча да, шулай ук район предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары җитәкчеләренең үтенечнамәсе буенча да кабул ителә (1, 2 нче кушымталар). Рәхмәт хаты белән бүләкләү турындагы үтенечнамәгә түбәндәгеләр кушып бирелә:

- гражданнар өчен – тәгаен казанышлары һәм хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр күрсәтелгән җентекле характеристика;

- хезмәт коллективлары һәм оешмалары өчен - оешма казанышлары турында белешмәләр булган мәгълүмат, юбилей датасы белән бәйле рәвештә бүләкләгәндә - оешмага нигез салыну датасы турында белешмә.

5. Үтенечнамәдә гражданнар һәм хезмәт коллективларының район һәм аның

халкы алдындагы казанышлары (уңышлары) турында әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән белешмәләр булырга тиеш.

Үтенечнамәдә Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты белән бүләкләүгә тәкъдим ителүче гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме паспорт мәгълүматлары буенча рус һәм татар телләрендә языла (татар телендә - Россия Федерациясе гражданы паспортының гражданның шәхесе турында белешмәләр булган кушымтасы булган очракта), вазыйфасы хезмәт кенәгәсендәге язмалар нигезендә, коллективлары бүләкләүгә тәкъдим ителгән органның яки оешманың исеме нигезләмәгә, шәхси эшмәкәр буларак физик затны дәүләт теркәве турында таныклыкка, органның яисә оешманың уставына яки башка оештыру документына ярашлы рәвештә языла.

Үтенечнамәне тутырганда нинди дә булса кыскартулар, аббревиатуралар, төгәлсезлекләр һәм төзәтүләр рөхсәт ителми.

Үтенечнамәгә имза салучы затлар анда күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеген тәэмин итәләр.

6. Әлеге бүләкләүгә предприятиеләрдән, оешмалардан бүләкләүләре булган, тармакта кимендә 3 ел эшләгән затлар (күренекле казанышларда чагыла торган аерым очраклардан тыш) тәкъдим ителә.

7. Рәхмәт хаты ике дәүләт теленең берсендә: рус һәм татар телендә языла. Үтенечнамә Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хатын рәсмиләштерү күздә тотыла торган телдә рәсмиләштерелергә тиеш.

8. Юбилей даталары уңаеннан гына Рәхмәт хаты белән бүләкләүгә тәкъдим итү рөхсәт ителми.

9. Рәхмәт хаты белән бүләкләү турындагы үтенечнамә тапшыру датасына кадәр 2 атнадан да соңга калмыйча Арча муниципаль районы башлыгына тапшырыла.

10. Рәхмәт хаты Арча муниципаль районы башлыгы тарафыннан имзалана.

11. Рәхмәт хаты белән бүләкләү Арча муниципаль районы башлыгы карары нигезендә башкарыла. Бер оешманың берничә хезмәткәренә үтенечнамә кергән очракта, Арча муниципаль районы башлыгының бер карарын рәсмиләштерү рөхсәт ителә.

12. Үтенечнамә түбәндәге очракларда кире кагыла:

а) Рәхмәт хаты белән бүләкләү өчен нигезләр булмау;

б) үтенечнамәдә булган белешмәләрнең дөрес булмавы ачыклану;

в) бүләкләүгә тәкъдим ителгән оешманың заты вафат булу яисә коллектив бетерелү;

г) җинаять кылган өчен бүләкләүгә тәкъдим ителгән затның закон көченә кергән суд карары нигезендә гаепләнүе.

13. Арча муниципаль районы алдындагы яңа казанышлары өчен кабат бүләкләү, район, республика, халыкара масштабтагы уңышлы әзерләнгән һәм уздырылган массакүләм чаралар һәм акцияләрдән тыш, алдагы бүләкләүдән соң 4 елдан да иртәрәк булырга мөмкин түгел.

14. Рәхмәт хаты Арча муниципаль районы башлыгы тарафыннан яки аның күрсәтмәсе буенча җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары, Арча район Советы депутатлары тарафыннан тантаналы шартларда тапшырыла.

15. Рәхмәт хаты белән бүләкләү турындагы карар массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла.

16. Рәхмәт хатларын рәсмиләштерү, исәпкә алу һәм теркәү Башкарма комитетның оештыру-гомуми бүлеге тарафыннан башкарыла.

17. Рәхмәт хатын югалткан очракта, дубликат бирелми.

## II. Рәхмәт хатының тасвирламасы

Рәхмәт хаты бланкы альбом ориентирлашуының А4 форматындагы тыгыз кәгазь битеннән гыйбарәт. Рәхмәт хаты бланкы периметры буенча рамка белән уратып алынган. Бланк уртасында өстә Арча муниципаль районы гербы сурәтләнгән. Астарак «Рәхмәт хаты» исеме, аннары бүләкләнүче затның исеме, атасының исеме күрсәтелгән. Астарак, бүләкләнүченең кыскача казанышларын күрсәтеп, рәхмәт белдерү һәм теләкләр язылган Рәхмәт хаты тексты урнаштырылган.

Рәхмәт белдерү текстыннан астарак Арча шәһәрендәге истәлекле урыннарның көмеш төсендәге контурлы сурәте урнаштырылган.

Бланк уртасында аста имза, «Арча муниципаль районы башлыгы» сүзләре һәм имзаның Арча муниципаль районы башлыгының исеме һәм фамилиясе, атасының исеменнән торган аңлатмасы язылган.

Астарак «Арча» сүзе урнашкан һәм бүләкләү елы өтер аша күрсәтелгән.

Рәхмәт хатында язмалар Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә - рус һәм татар телендә башкарыла.

Рәхмәт хаты бланкы өчен көмеш һәм кара төсләрдәге Times New Roman хәрефләре кулланыла.

Рәхмәт хаты бланкы өчен өстәмә атрибут - пыялалы рамка каралган.

*Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты турындагы нигезләмәгә*
*1 нче кушымта*

Арча муниципаль районы башлыгы

_______________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

ҮТЕНЕЧНАМӘ

Сездән Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты белән бүләкләү өчен

_____________________________________________________________________________

(бүләкләүгә тәкъдим итү нигезе)

_____________________________________________________________________________
бүләкләү өчен кандидатның эшләү урыны, [3]вазыйфасы)

_____________________________кандидатурасын каравыгызны сорыйм.
(ФИАи, туу датасы[4])

Кушымта: билгеле бер казанышларын һәм белешмәләрне күрсәтеп, хезмәт эшчәнлеге турында характеристика.

Оешма,
предприятие, учреждение һ.б. җитәкчесе

(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

---

[3] *Әгәр орган яисә оешманың исеме органның гамәлгә кую документларында татар телендә күрсәтелгән булса, оешманың исеме рус һәм татар телләрендә күрсәтелә.*

[4] *Гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме рус һәм татар телләрендә күрсәтелә.*

*Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты турындагы нигезләмәгә*
*2 нче кушымта*

Арча муниципаль районы башлыгы

______________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

ҮТЕНЕЧНАМӘ

Сездән Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты белән бүләкләү өчен

____________________________________________________________________
(бүләкләүгә тәкъдим итү нигезе)

____________________________________________________________________
(оешманың тулы исеме)[5]

үтенечнамәне каравыгызны сорыйм.

Кушымта: казанышлар турында белешмәләр, бүләкләү датасына бәйле рәвештә - оешмага нигез салыну датасы турында белешмә.

Оешма,
предприятие, учреждение һ.б. җитәкчесе

(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

____________________
[5] *Әгәр орган яисә оешманың исеме органның гамәлгә кую документларында татар телендә күрсәтелгән булса, оешманың исеме рус һәм татар телләрендә күрсәтелә.*

*Арча район Советының*
*31 гыйнвар 2024 ел, № 262*
*карарына 5 нче кушымта*

Арча муниципаль районы бүләкләре белән бүләкләү өчен тапшырыла торган материалларны карау комиссиясе
СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Нуриев Илшат Габделфәртович | - Арча муниципаль районы башлыгы, комиссия рәисе; |
| Мөхәмәтова Алсу Фирдәүсовна | - Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Фәйзрахманова Эльвира Минзаһитовна | - Башкарма комитет аппаратының гомуми-оештыру бүлеге башлыгы, комиссия секретаре (килешү буенча). |
| ***Комиссия әгъзалары:*** | |
| Гапдерахманова Гүзәл Әдһәмовна | - Арча район Советының оештыру-гомуми бүлеге җитәкчесе; |
| Галимуллин Радик Наилевич | - Арча район Советы аппараты җитәкчесе; |
| Гатиятов Ренат Мансурович | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча). |

Арча район Советының
31 гыйнвар 2024 ел, № 262
карары белән расланды

# РӘХМӘТ ХАТЫ



Арча муниципаль
районы башлыгы

И.Г. Нуриев

*Арча район Советының*
*31 гыйнвар 2024 ел, № 262*
*карары белән* расланды

# МАКТАУ ГРАМОТАСЫ



**Арча муниципаль районы башлыгы** **И.Г. Нуриев**

*Арча район Советының*
*31 гыйнвар 2024 ел, № 262*
*карарына 5 нче кушымта*

Арча муниципаль районы бүләкләре белән бүләкләү өчен тапшырыла торган материалларны карау комиссиясе
СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Нуриев Илшат Габделфәртович | - Арча муниципаль районы башлыгы, комиссия рәисе; |
| Мөхәмәтова Алсу Фирдәүсовна | - Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Фәйзрахманова Эльвира Минзаһитовна | - Башкарма комитет аппаратының гомуми-оештыру бүлеге башлыгы, комиссия секретаре (килешү буенча). |
| ***Комиссия әгъзалары:*** | |
| Гапдерахманова Гүзәл Әдһәмовна | - Арча район Советының оештыру-гомуми бүлеге җитәкчесе; |
| Галимуллин Радик Наилевич | - Арча район Советы аппараты җитәкчесе; |
| Гатиятов Ренат Мансурович | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча). |

Арча муниципаль районы
башлыгы урынбасары А.Ф.Мөхәмәтова